**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
**Камско-Устьинского**
**муниципального района**

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма комитеты**

422835, Иске Барыш авылы, Үзэк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

---

# КАРАР

«04» декабрь 2025 ел № 32

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибен раслау турында»31.03.2020 №7 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актта коррупциоген факторларны бетерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «МНПАДА ачыкланган коррупциоген факторлар турында» 12.09.2025 № 09/13-09/4246 хаты нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.03.2020 № 7 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пунктта:
дүртенче һәм бишенче абзацларны төшереп калдырырга;
түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәгән һәм (яисә) муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый

сәясәте максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторының) әһәмиятен үзгәртүгә түләүчеләр өчен каралган ташламалар кертемен бәяләүнең уңай күрсәткечләренә ирешмәгән очракта һәм (яисә) югарырак күрсәткечләргә ирешү муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелеге буенча муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча салым чыгымы кураторы җирле администрациягә ташламаларны саклап калу (төгәлләштерү, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр тапшырырга тиеш.”;

1.1. 15.1 нче пунктны гамәлдән чыгару;

1.2. 16.1 нче пункт. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне түбәндәге мөнәсәбәттә үткәрмәскә:

А) муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнары;

б) муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру вакытына фискаль характеристикалар булмаган муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары;

в) муниципаль берәмлекнең гамәлдә булу срогы бер елдан кимрәк булган ташламаларга бәйле салым чыгымнары.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе И.Р.Җиһаншин